ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.01.2023 г. Заинск № 13

**«Зәй муниципаль районының авыл җирлекләре территориясендә урнашкан муниципаль торактан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондының торак урыннарын карап тоткан һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайламаган торак милекчеләре өчен түләү күләме турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы авыл җирлекләре халкы өчен расларга:

социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннарның милекчеләре өчен торак урынын карап тотуга түләү күләмен 1 нче кушымта нигезендә;

Зәй муниципаль районы муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләмен (наемга алу өчен түләү) 2 нче кушымта нигезендә.

2. Тороктан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме 2018 елның 26 ноябрендәге 1758 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән (2022 елның 22 декабрендәге 667 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Зәй муниципаль районда социаль наем килешүләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннарын биләүчеләр өчен тораклан файдаланган өчен түләү күләмен (наем өчен түләү) исәпләү методикасы нигезендә исәпләнә.

3. «Зәй муниципаль районының авыл җирлекләре территориясендә урнашкан муниципаль тораклан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондының торак урыннарын карап тоткан һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайламаган торак милекчеләре өчен түләү күләме турында» 2021 елның 22 декабрендәге 775 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Юрист

М.М. Хәбибуллин

**Зәй муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**2020 елның __13. 01__**
**__13__ номерлы карарына**
**1 нче кушымта**

**Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча файдаланучылар өчен торакны тоту өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайламаган торак милекчеләре өчен торак өчен, торакны карап тоту өчен түләү күләме**

| № п/п | Хезмәтнең исеме | Хезмәтне үлчәү бердәмлеге | Хезмәт күрсәтүне исәпләү өчен тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 1.01.2023 ел-30.06.2023ел | 1.07.2023 ел - 31.12.2023ел. |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 1,76 | 1,76 |
| 2 | Торак бинага агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 2,39 | 2,39 |
| 3 | Йорт эчендәге санитар-техник челтәрләргә агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 1,76 | 1,76 |
| 4 | Йорт эчендәге үзәк җылыту челтәренә агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 1,56 | 1,56 |
| 5 | Йорт эчендәге газ белән тәэмин итү челтәренә агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 0,25 | 0,25 |
| 6 | Йорт эчендәге электр челтәренә агымдагы ремонт | аена торакның гомуми мәйданының кв. метрына | 0,98 | 0,98 |

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 13 01
13 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Зәй муниципаль районында муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча файдаланган өчен түләү күләме (наем өчен түләү)**

| Адрес | | **Торак урынны наемга алган өчен түләү күләме** (аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. метрыннан) 1.01.2023 елдан 31.12.2023 елга кадәр. |
|---|---|---|
| 1 | Александр Бистәсе, Яңа урам, 35 йорт | 9,8 |
| 2 | Бохарай, Ромашкино, 1 йорт | 9,8 |
| 3 | Бохарай, Ромашкино, 2 йорт | 9,8 |
| 4 | Бохарай, Ромашкино, 3 йорт | 10,0 |
| 5 | Поручик, Яңа урам, 11 йорт | 9,8 |
| 6 | Поручик, Яңа урам, 12 йорт | 9,8 |
| 7 | Сарсаз-Баграж, Яшьләр урамы, 1 йорт | 9,8 |
| 8 | Сарсаз-Баграж, Яшьләр урамы, 2 йорт | 9,8 |
| 9 | Сарсаз-Баграж, Яшьләр урамы, 3 йорт | 9,8 |
| 10 | Урсай, Үзәк урам, 3 йорт | 9,8 |
| 11 | Урсай, Үзәк урам, 4 йорт | 10,0 |
| 12 | Якты Күл, Академик Гортышев урамы, 7 | 10,0 |
| 13 | Якты Күл, Академик Гортышев урамы, 9 | 10,0 |
| 14 | Иске Маврин, Үзәк урам, 1 йорт | 9,8 |
| 15 | Иске Маврин, Үзәк урам, 2 йорт | 9,8 |
| 16 | Бигеш, Гагарин урамы, 125 йорт | 10,0 |
| 17 | Бохарай, Яңа урам, 4 йорт | 10,3 |